# Режим вакытларында балалар фольклоры

**Белем бирү эшчәнлегеннән тыш вакытларында бакчабызда балалар фольклоры киң кулланыла. Бу бигрәк тә балалрның сөйләм телен камилләштерү өчен кирәк. Татар, рус халкының шигырьгә салган юаткычлары, эндәшләр, такмазалар, иярмешләр, әйтенүләр бик күп. Тәрбиячеләр генә түгел, мәдәният йортында фольклор түгәрәген алып баручы Гөлсем Рабгутдинова да безнең белән кулга-кул тотынып эшли. Музыка җитәкчесе иртәнге гимнастиканы баянда татар халык көйләренә, шигырьләр кулланып үткәрә.**

















